АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06.12.2022г. п.г.т. Алексеевское № 149

**Татарстан Республикасы«Алексеевск муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга кертелгән үзгәрешләргә һәм өстәмәләргә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Уставының XVI бүлеге нигезендә

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүне беренче укылышта кабул итәргә. (1 нче кушымта).

Алар өстендә эшләүне тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне исәпкә алып дәвам итәргә.

2. «Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Алексеевск муниципаль районы Советы карарына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашуын расларга. (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: https://alekseevskiy.tatarstan.ru/resheniya-soveta-alekseevskogo-munitsipalnogo.htm.

4. Законлылык, регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы буенча даими депутат комиссиясенә (Тюкарев Ю.И.) әлеге карарга кергән тәкъдимнәрне исәпкә алуны, гомумиләштерүне һәм карауны йөкләргә.

5. Алексеевск муниципаль районы Советы депутатларының төзәтмәләр рәвешендәге тәкъдимнәре комиссиягә 2022 елның 29 декабренә кадәр кертелә дип билгеләргә.

6. Гражданнарның әлеге карарга тәкъдимнәре комиссиягә Ф.И. А. күрсәтелеп, туу елы, авторның адресы, түбәндәге адрес буенча язмача җибәрелә дип билгеләргә: пгт. Алексеевск штп, Совет мәйданы, 3.

7. 2023 елның 09 гыйнварына 11-00 сәгатькә Алексеевск муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча халык алдында тыңлауларны билгеләргә. муниципаль район Советының утырышлар залында.

Гавами тыңлаулар,Алексеевск муниципаль районы Советының 2006 елның 14 декабрендәге 126 номерлы карары белән расланган,Алексеевск муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе нигезендә үткәрелә.

8. Комиссиягә район Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм гражданнарның әлеге карарга тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, аларны эшләп бетерергә һәм 2023 елның 16 гыйнварына кадәр район Советы каравына кертергә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

10. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса, үз көченә керә.

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А.Демидов**